СОВЕТ УРАЗБАХТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.1а, с. Уразбахтино,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422155

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРАЗБАХТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., 1 нче а йорт, Уразбахты авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422155

тел.(факс): (85563) 2-86-36; e-mail: UrBah.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар — Решение

20.06.2023 ел — №2-26

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге муниципаль милкенә карата концессион килешү төзү турында карар кабул итүгә ризалык бирү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Уразбахты авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Уразбахты авыл җирлеге башкарма комитетына коммуналь инфраструктура һәм башка коммуналь хуҗалык объектларына, шул исәптән су белән тәэмин итү объектларына, үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү системаларына, мондый системаларның аерым объектларына хезмәт күрсәтүгә концессион килешү төзү турында карар кабул итүгә ризалык бирергә.

2. 1 нче кушымтада бирелгән күчемсез мөлкәтне концессион килешү объектлары итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар халыкка җиткерелгән (басылып чыккан) көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге башлыгы Р.Г.Шәйхетдиновка йөкләргә.

Уразбахты авыл җирлеге Советы рәисе,
җирлек башлыгы /Р.Г.Шәйхетдинов/

Мамадыш муниципаль районы
Уразбахты авыл җирлеге Советының
20.06. 2023 ел, № 2-26 карарына
1 нче кушымта

## Объекты концессионного соглашения, в том числе технико-экономические показатели, техническое состояние, срок службы

| № п/п | Наименование объекта | Кадастровый номеры | Адрес местоположения (нас.пункт/ул.) | Техн.параметры (площадь/диаметр/высота /протяженность и т.д.) | Гамәлгә керү елы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Артезиан скважинасы | 16:26:620101:670 | Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Уразбахты авылы | Тирәнлеге 48 м | 1982 |
| 2 | Суэтем башнясы | 16:26:620101:666 | Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Уразбахты авылы | Биеклеге 12 м | 1987 |
| 3 | Су үткәргеч челтәре | 16:26:000000:4426 | Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Уразбахты авылы | Озынлыгы 4487 м. | 1987 |